РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУСЛЮМОВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ТОЙГИЛЬДИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТОЙГЕЛДЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР № 9**

Тойгелде авылы « 22 » март 2024г.

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлегенең «2021 елның «29» июль 16 нчы номерлы «Агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кыскартуга, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газоннарны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Прокуратурасының 2024 елның 18 мартындагы 02-08-01-2024 номерлы протестын карап чыгып, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлегенең «2021 елның «29» июлендәге 16 нчы номерлы «Агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кыскартуга, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газоннарны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.5.2.1 пунктының җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлеге Советының «24» февраль 2021 елның 12 нче номерлы «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә керми торган яшеллекләрне кисү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында » Мөслим муниципаль районының Тойгелде авыл җирлеге муниципаль берәмлеге бюджетына кертелергә тиешле түләүләрне исәплəү өчен билгеләнгән (алга таба – торак пункт) физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге яшеллекләрне законлы рәвештә тартып алганда компенсацион яшелләндерү өчен, шулай ук торак пункт территориясендә урнашкан яшеллекләргә законсыз зыян килү яки юк ителү нәтиҗәсендә компенсация бәясен түләү өчен счет төзи;»;

1.2. 3.5.2.2 пунктының дүртенче абзацында «кирәк булганда» сузләрен төшереп калдырырга;

1.3. 3 бүлектә түбәндәге эчтәлекле 3.8 пунктны өстәргә:

«3.8. Муниципаль хезмәтне алдан күрсәтү режимында (проактив режимда) күрсәтү очраклары һәм тәртибе.

Муниципаль хезмәт күрсәтүне алдан ук (проактив) режимда бирү каралмаган.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының муниципаль берәмлеге рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге Карар рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Мөслим муниципаль районының Тойгелде авыл җирлеге Башкарма комитет җитәкчесе** **Фәйзуллина Э.Н.**